**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1902**
**20.04.2020**

Башкарма комитетның 2014 елның 21 июлендәге 4251 номерлы карары белән расланган җир участогының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 37, 39 статьялары, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 21 июлендәге 4251 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3283 номерлы, 2019 елның 5 июлендәге 3445 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган җир участогының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147);

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышулар яки җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/16 номерлы карары (алга таба – Җәмәгать тыңлаулары оештыру һәм үткәрү тәртибе) («Челнинские известия», 21.11.2018 № 84);

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясе турында» 2008 елның 1 декабрендәге 3791 номерлы карары (алга таба – Җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия турында нигезләмә);»;

2) 2.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр:<br>1) җир участогына карата суд бәхәсе булу;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Регламентның 2,6 пункты буенча каралган, норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар алынмау.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) гариза бирүченең җир участогы урнашмаган урын буенча җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итүе;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җир участогына хокукы булмаган зат мөрәҗәгать иткән, федераль әһәмияткә ия объектлар, региональ әһәмияткә ия объектлар, җирле әһәмияткә ия объектлар урнаштыру өчен җир участогы дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм (яки) өченче затларның хокуклары йөкләнмәгән (сервитут һәм җәмәгать сервитутыннан тыш) җирләрдән һәм (яки) җир участокларыннан барлыкка килгән очрактан тыш;<br>3) территорияне планлаштыру буенча документлар булмау (ул булмаса капиталь төзелеш объектларын урнаштыру рөхсәт ителмәгән очракта);<br>4) җир участогының максатчан билгеләнешен үзгәртү гамәлдәге закон таләпләре, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, санитария, экологик һәм янгынга каршы кагыйдәләр һәм нормалар бозылуга китерә;<br>5) җир участогының сорала торган рөхсәт ителгән файдалану төре Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төрләренә туры килмәү;<br>6) җир участогының рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү сорала торган рөхсәт ителгән файдалану төрендәге җир участоклары бирүнең җир законнарында билгеләнгән | 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>РФ Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясындагы 8, 9 бүлекләр;<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия турында нигезләмә |

| | | |
|---|---|---|
| | тәртибе бозылуга китерәчәк;<br>7) җир участогы төзелеш белән бәйле булмаган максатларга бирелгән (төрен үзгәртү әлеге җир участогында капиталь объект төзүне күздә тоткан очракта);<br>8) җир участогында рөхсәтсез төзелгән корылма булу;<br>9) җир участогына хокукы булган башка затларның рөхсәте булмау (җир участогына хокукы булган затлар берничә булган очракта);<br>10) җир участогына залог йөкләмәсе (ипотека) рәвешендә салынган йөкләмә булу (залог тотучының ризалыгы булмаган очракта). | |

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов